ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы Гаилә кодексына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 19 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Гаилә кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 9 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 5, № 7; 2014, № 4, № 6 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш), 2018, № 22 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяда:
а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“1. Никахлашу өйләнешүче затларның шәхси катнашында, граждан хәле актларын теркәү органына гариза биргән көннән соң бер ай узгач һәм унике айдан да соңга калмыйча, өйләнешүче затлар никахлашу турында гариза биргәндә билгеләгән датада һәм вакытта башкарыла.”;
б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“2. Нигезле сәбәпләр булган очракта никахлашуны дәүләт теркәвенә алу урыны буенча граждан хәле актларын теркәү органы никахлашу турында гариза бирелгән көннән алып бер ай узганчы ук никахлашуны рөхсәт итәргә мөмкин.”;

2) 74 статьяның 3 өлешендә “физик затларның кертемнәрен” сүзләрен “кертемнәрне” сүзенә алмаштырырга;

3) 102 статьяда:
а) исемендә “бурычын” сүзеннән соң “һәм (яисә) алиментларны вакытында түләмәгән өчен неустойка бурычын” сүзләрен өстәргә;
б) 1 өлештә “алимент бурычын түләүдән азат итү яисә бу бурычны киметү” сүзләрен “алимент бурычын һәм (яисә) алиментларны вакытында түләмәгән өчен неустойка бурычын түләүдән азат итү йә алимент бурычын һәм (яисә)

алиментларны вакытында түләмәгән өчен неустойка бурычын киметү” сүзләренә алмаштырырга;

в) 2 өлештә “бурычын” сүзеннән соң “һәм (яисә) алиментларны вакытында түләмәгән өчен неустойка бурычын” сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, бу законның 1 статьясындагы 2 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пункты 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 30 ноябрь
№ 91-ТРЗ